МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__________________ Казан ш. № 614 од

Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” № 210-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының көчләрен югалтуын тану турында” 2022 елның 28 февралендәге № 175 карарына туры китереп,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына буйсынучы өстәмә белем бирүнең гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары җитәкчеләренә бу Регламентка таянып эшләргә.
3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Фәнни тикшеренүләр, инновацияләр һәм һөнәри компетенцияләрне үстерү бүлегенә (Ф.Ф. Козырева) боерык кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнүче өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2021 елның 16 декабрендәге 1060 од номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.
5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Ю.И. Әдһәмовага йөкләргә.

Министр И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
17.08.2022 ел, № 614 од
боерыгы белән расланды

Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында өстәмә белем бирүнең гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алырга хокуклы затлар булып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән Оешмага мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар яки аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – Гариза бирүчеләр) тора.

Гариза бирүчеләрнең категорияләре:

14 яшькә җиткән затлар;

балигъ булмаган затларның ата-аналары (законлы вәкилләре).

Гариза бирүченең мәнфәгатьләре буенча эш итәргә Россия Федерациясе законнарына туры китереп рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гамәл кылучы ышанычлы зат хокуклы.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, профильләштерү (Гариза бирүченең хезмәтне күрсәтүче орган тарафыннан уздырыла торган анкета нәтиҗәсендә ачыкланган билгеләренә туры килүче дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә, Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартлары

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтү Татарстан Республикасында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары (алга таба – Оешма) тарафыннан башкарыла.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

Оешмага кабул итү турында боерыктан өземтә (Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән форма буенча);

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрнамә (Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу ысуллары:

2011 елның 6 апрелендәге “Электрон имза турында” 63-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) туры китереп, Оешманың вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә;

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталы (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (алга таба – Республика порталы), Татарстан Республикасы “Электрон мәгариф” мәгълүмат системасындагы (алга таба – “Электрон мәгариф” системасы) шәхси кабинетка җибәреп.

2.3.3. Гариза бирүченең сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Оешма җибәргән электрон документның кәгазьгә бастырып чыгарылган, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган нөсхәсе рәвешендә КФҮдән алынырга мөмкин.

2.3.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында, электрон документ рәвешендә яки электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алуга хокуклы.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы гаризаны һәм документларны теркәгән мизгелдән башлап тугыз эш көне тәшкил итә – Гариза бирүче Оешмага шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә, яки керү (кабул итү) сынаулары уздыру зарурлыгы булмаганда, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Оешмага КФҮ, Бердәм портал, Республика порталы аша кергән очракта.

2.4.2. Кабул итү турында боерыктан өземтә Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен (Гариза бирүче өчен Оешмага кәгазьдә яисә электрон рәвештәге өстәмә формаларын бирү зарурлыгы юк) гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар белән чагыштырганнан соң бирелә, чагыштыру гамәлгә ашырыла:

1) керү (кабул итү) сынаулары уздыру зарурлыгы булганда – керү (кабул итү) сынаулары узган мизгелдән алып дүрт эш көне эчендә;

2) керү (кабул итү) сынаулары уздыру зарурлыгы булмаганда – дәүләт хезмәте күрсәтү турында боерык чыгарылган мизгелдән алып дүрт эш көне эчендә.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрнамә Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар чыгарылганнан соң бер эш көне эчендә җибәрелә яки Гариза бирүчегә Оешмага шәхсән үзе килгәч тапшырыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар чыгарылган көннән иртәрәк түгел.

2.4.4. Оешма ел саен, бу Регламент һәм Оешманың оештыру-боеру актына туры китереп, агымдагы уку елына төп җыю һәм өстәмә җыю (зарурлык булган очракта) вакытларын билгели. Буш урыннар булганда, Оешмага язылу уку елы дәвамында барырга мөмкин.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору законнар белән күздә тотылмаган.

2.5. Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуга җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза:

кәгазьдәге документ рәвешендә (Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча);

Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, “Электрон имза турында” 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган электрон документ (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла) рәвешендә;

2) Гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ (КФҮгә яисә Оешмага мөрәҗәгать иткәндә тапшырыла);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, Гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта Гариза бирүченең вәкиленең шәхесен таныклаучы документ;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, Гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта Гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

5) өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча кергәндә, законнар белән күздә тотылган очракларда, сәнгатьнең аерым төрләре белән шөгыльләнү өчен медицина ягыннан каршылыклар булмау турында документлар;

6) балигъ булмаган баланың чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән туу турындагы таныклыгы күчермәсе, аның рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе (булган очракта).

Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җайлаштырылган гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган Оешмаларда дәүләт хезмәте алу өчен, ата-аналар (законлы вәкилләр) адаптив белем бирү программасы буенча укуга өстәмә рәвештә психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсен тапшыралар (мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен).

Чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Тәрҗемәнең дөреслеге, тәрҗемәче имзасының чынлыгы нотариат турында Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә раслана, яисә 1961 елның 5 октябрендәге “чит ил рәсми документларын легальләштерү таләбен гамәлдән чыгара торган Гаага конвенциясе” нигезендә апостиль белән таныклана.

2.6.2. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Гариза бирүче булып тормаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә андый шәхси мәгълүматларны эшкәртү әлеге зат ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, дәүләт хезмәтен алуга мөрәҗәгать иткәндә Гариза бирүче өстәмә рәвештә әлеге затның яки аның законлы вәкиленең әлеге затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы алынганны раслаучы документлар тапшыра. Ризалык алуны раслаучы документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә бирелергә мөмкин.

2.6.3. Гариза һәм кушып бирелә торган документлар Гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь чыганакларда һәм Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә;

3) Оешмада яки Министрлыкта шәхсән кабул итү вакытында.

2.6.4. Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, Гариза бирүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен, Гариза бирүчегә “Электрон формада дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының үзара мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы” (алга таба – ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан түбән булмаган дәрәҗәдә исәп язмасын расларга кирәк.

2.6.5. Гариза бланкының электрон формасы Оешманың рәсми сайтына урнаштырылган.

2.6.6. Гаризада түбәндәге мәҗбүри белешмәләр күрсәтелә:

1) фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

2) туу датасы;

3) Гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документның реквизитлары;

4) шуның буенча укыту гамәлгә ашырылачак өстәмә гомуми белем бирү программасы;

5) инвалидлыгы яки сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән булу сәбәпле, керү сынауларын уздырганда, укырга керүчегә махсус шартлар тудыру зарурлыгы.

Гаризада шулай ук мәгариф эшчәнлеге алып баруга лицензия, белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген дәүләт аккредитацияләве турында таныклык һәм аларга кушымта күчермәләре белән танышу (шул исәптән гомуми файдаланудагы мәгълүмат системалары аша), яисә күрсәтелгән таныклыкның күчермәсе булмау фактлары теркәлә. Танышу факты Гариза бирүченең шәхси имзасы белән раслана.

Гариза бирүченең имзасы белән түбәндәгеләр дә раслана:

укучының Оешмага кабул итүгә бәйле рәвештә алынган шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык;

Оешма уставы, мәгариф эшчәнлеге алып баруга лицензия, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, өстәмә гомуми белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны, укучыларның хокукларын һәм бурычларын регламентлаучы башка документлар белән танышу.

2.6.7. Гариза һәм кушып бирелә торган документлар Гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша кәгазь чыганакларда һәм Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә;

3) Оешмада яисә Министрлыкта шәхсән кабул итү вакытында.

2.6.8. Гариза бирүчеләрдән билгеле бер иҗади сәләт, физик һәм (яисә) психологик сыйфатлар таләп итә торган белем бирү программалары буенча укуга кабул иткәндә керү сынаулары үткәрелә.

2.6.9. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле органнардан алына:

СНИЛС номеры турында мәгълүмат;

инвалидлык турында мәгълүмат;

опека билгеләнгәнне раслаучы документ;

балигъ булмаган баланың тууы турында мәгълүмат.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы документларны Гариза бирүче үз теләге белән тапшырырга хокуклы.

Күрсәтелгән документлар Гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга һәм, Регламентның 2.6.3 пункты билгеләгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламент белән күздә тотылган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып торалар:

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплекты тапшырылган;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар көчләрен югалткан;

документлардагы текстта Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар;

документларда хезмәт күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар бар;

гаризаның мәҗбүри юллары төгәлсезлекләр белән тутырылган;

документларның документ текстын тулысынча укырга һәм (яисә) документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирми торган электрон сурәтләрен тапшыру;

гариза һәм Гариза бирүченеке яисә Гариза бирүченең вәкиленеке булмаган электрон имзадан файдаланып имзаланган электрон рәвештәге башка документларны бирү;

электрон гариза Гариза бирүченең мәнфәгатьләрен чагылдыру вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан бирелгән;

гариза кергән мизгелгә элегрәк җибәрелгәне буенча дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бетмәгән элегрәк теркәлгән гаризага охшаган гариза кергән.

2.7.2. Дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Гариза бирүчегә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка һәм (яисә) КФҮгә яисә кәгазь битендә җибәрелә.

2.7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның, Оешманың рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр күздә тотылмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

гаризада һәм аңа кушып бирелгән документларда тәңгәл килмәгән мәгълүматлар булу;

Гариза бирүченең категориясе Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затлар даирәсенә туры килмәү;

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның формасы яисә эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәве;

сәнгатьнең аерым төрләре буенча программаларны үзләштерү өчен медицина ягыннан каршылыклар булу;

Оешмада буш урыннар булмау;

уку турында килешү төзү өчен шәхсән килү зарурлыгы турында хәбәрнамә алганнан соң дүрт эш көне эчендә Оешмага килмәү;

Оешмага керү (кабул итү) сынауларын узарга килмәү;

Оешмада керү (кабул итү) сынаулары үткәрелгән көнне яисә керү (кабул итү) сынауларын үткәрү кирәк булмаган очракта килешү имзаланган көнне документларның төп нөсхәләрен күрсәтмәү;

керү (кабул итү) сынауларының нәтиҗәләре тискәре булу;

Гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматның ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек нәтиҗәсендә алынган мәгълүматка туры килмәве.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның, Оешманың рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган түләү күләме һәм аны түләтү ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә чиратта көтүнең максималь срогы

2.10.1. Дәүләт хезмәте алуга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогы

2.11.1. КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза биргән көнне Гариза бирүчегә КФҮ АИСыннан гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы теркәү номеры һәм электрон гариза бирү датасы белән расписка бирелә.

2.11.2. Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, Гариза бирүче гаризаны теркәү көнендә Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслаучы хәбәрнамә ала, анда гаризаны теркәү номеры һәм бирү датасы күрсәтелгән була.

2.11.3. Оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәү Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз керә алуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчеп йөрү юллары).

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы Гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз керә алуы максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

2) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясенең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлеге чикләнгәнлекне исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-нокталы шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) аның махсус өйрәтелгәнлеген раслый һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгәнлеген раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган формада һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда, озатып йөрүче этне кертү;

7) Министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтүе.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чараларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация үткән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашканлыгы;

2) кирәкле санда белгечләрнең, шулай ук Гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның булуы;

3) мәгълүмат стендларында, Министрлыкның, Оешманың рәсми сайтларында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

4) Министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга биналарның инвалидлар өчен керә-чыга алуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга хезмәтләрне башка затлар белән бертигез алырга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм итүе.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) Оешма, Министрлык, КФҮ хезмәткәрләренең Регламентны бозуына карата нигезле шикаятьләр булмау.

4) Гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) Гариза бирүченең КФҮ хезмәткәрләре белән дәүләт хезмәте күрсәткәндә аралашуы барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

4.2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алу зарурлыгы булган очракта – бер тапкыр.

Гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән дәүләт хезмәте күрсәткәндә бер аралашуы дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып бәяләргә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны Гариза бирүче Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетында, КФҮдә алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматтан һәм башка документлардан файдалану Гариза бирүченең Порталдагы шәхси кабинетында алдан авторизацияләнмичә башкарыла.

Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта авторизацияләнгәннән соң Гариза бирүче түбәндәге мөмкинлеккә ия:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза бирергә;

кирәк булганда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон сурәтләрен (график файлларны) беркетергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алырга.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон формада бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, Гариза бирүченең гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен, Гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү процедурасын узарга кирәк. ЕСИАда алдан теркәлүнең онлайн формасы “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтта урнаштырылган (“Интернет” челтәрендә сайтның доменлы исеме – esia.gosuslugi.ru/).

ЕСИАда (физик зат буларак) теркәлү процедурасын үткәннән соң, Гариза бирүче – физик зат, гади электрон имза кулланып, Бердәм порталда, Республика

порталында авторизацияләнергә тиеш. Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта авторизациядән соң, Гариза бирүче элегрәк бирелгән гаризаларны һәм электрон рәвештә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен күрү мөмкинлеге ала.

2.13.4. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә белешмәләр бирү хакында

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, яшәү урынына яисә фактта яшәп тору (булу) урынына бәйсез рәвештә, Гариза бирүченең сайлавы буенча, экстерриториаль принцип буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә, Гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле башка документлар, шул исәптән электрон сурәтләре “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясындагы 1 нче өлешенең $7^2$ пункты нигезендә элегрәк расланган документларны һәм мәгълүматны бирергә;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларның үтәлү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен хәбәрнамә рәвешендә алырга;

е) Оешманың, Министрлыкның, КФҮнең, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карары һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәткәндәге карарларына һәм алар тарафыннан кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында, “Электрон мәгариф” системасында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада бирү зарурлыгыннан тыш башкарыла.

2.14.4. Гариза бирүчеләрнең КФҮдә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ элемтә үзәге телефоны аша башкарыла.

Гариза бирүчегә күпфункцияле үзәктә кабул итүнең билгеләнгән графигы чикләрендә кабул итү өчен теләсә кайсы буш көнгә һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Республика порталы, Бердәм портал ярдәмендә алдан язылу өчен, Гариза бирүчегә система тарафыннан сорала торган мәгълүматны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысын – булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

кабул итүнең теләгән датасын һәм вакытын.

Алдан языллып куйганда Гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүматлар Гариза бирүче шәхсән кабул иткәндә тапшырган документлардагыга туры килмәгән очракта, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан языллып куйганда Гариза бирүчегә раслау талонын бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан языллып куйганда, Гариза бирүчегә һичшиксез хәбәр ителә: ул килмәгән очракта кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан соң 15 минут узгач, алдан язылу юкка чыгарыла.

Гариза бирүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүдән тыш, Гариза бирүчедән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары

### 3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) Гариза бирүчегә консультация бирү;

2) Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

4) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү;

5) Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе;

7) техник хаталарны төзәтү.

### 3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Административ процедураны үтәү башлануга нигез булып Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) (алга таба – консультация бирүгә җаваплы вазыйфаи зат) булып тора:

Гариза бирүче Оешмага мөрәҗәгать иткәндә – Оешма хезмәткәре;

Гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәре;

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре.

3.2.2. Гариза бирүче Оешмага, КФҮгә шәхсән үзе, телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Гариза бирүче Оешманың http://edu.tatar.ru; КФҮнең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.2.3. Гариза бирүче Оешмага, Министрлыкка телефоннан, электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында, Оешманың, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Гариза бирүчегә мәгълүмат бирә.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнгән процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе булып торалар: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын кабул итү һәм карау

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны КФҮ аша кабул итү.

3.3.1.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать белән КФҮгә мөрәҗәгать итә һәм документларны Регламентның 2.6 пункты нигезендә тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

Гариза бирүче шәхесен таныклый;

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮ АИСта гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь чыганакта тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлый;

КФҮ АИСтан гаризаны бастырып чыгара;

Гаризаны Гариза бирүчегә тикшерүгә һәм имзалауга тапшыра;

имзалаудан соң, имзаланган гаризаны КФҮ АИСта сканерлый;

электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон сурәтләрен КФҮнең АИСына кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

Гариза бирүчегә документларның кабул ителүе турында расписка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып тора: җибәрүгә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре, Гариза бирүче КФҮнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән алып бер эш көне эчендә, Гариза бирүчедән кабул ителгән документлар пакетын электрон рәвештә (электрон эшләр пакетлары составында) Оешмага җибәрә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып торалар: Оешмага электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә бирү өчен, Гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Республика порталында авторизация үтә;

Бердәм порталда, Республика порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формада документларны яисә документларның электрон сурәтләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамганы куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.6.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып торалар: электрон хезмәттәшлек системасы аша Оешмага җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Оешманың документлар комплектын каравы.

3.3.3.1.Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе булып гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар килү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (алга таба – документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат) Оешманың боерыгы белән билгеләнә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, документлар каралуга кергәннән соң:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм “Документларны тикшерү” статусы бирә, бу Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетында чагыла;

электрон эшләрне, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада бирелгән документларны һәм документларның электрон сурәтләрен өйрәнә;

документларның комплектлылыгын, электрон сурәтләренең укылышлылыгын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (Гариза бирүче документларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон сурәтләрен тапшырган очракта).

Регламентның 2.7.1 пункты күздә тоткан нигезләр булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар (әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентка 3 нче кушымтадагы формада рәсмиләштерелсә) электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм, гариза кергән көннән алып бер эш көненнән соңга калмыйча, Гариза бирүченең Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әгәр көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турында карар проекты 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы аны кабул итү өчен нигез булып торган пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пункты күздә тоткан нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән, гаризаның керүе турында Гариза бирүчегә гаризаның керүче теркәү номерын, гаризаны алу датасын, аның белән бергә бирелгән документлар файлларының атамалары исемлеген, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу датасын үз эченә алган хәбәрнамә җибәрә.

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.3. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Административ процедураны үти башлауга нигез булып, Оешманың административ процедураны үтәүгә вәкаләтле вазыйфаи затының (хезмәткәренең) Оешманың Гариза бирүчедән алынган документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затыннан (хезмәткәреннән) документлар алуы тора.

Оешманың административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи заты (хезмәткәре) булып, документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат (алга таба – ведомствоара мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.4.2. Оешманың ведомствоара мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заты Регламентның 2.6.9 пункты күздә тоткан документлар һәм мәгълүматларны тапшыру турында мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Административ процедураларның үтәлү нәтиҗәләре булып торалар: хакимият органнарына һәм (яисә) хакимият органнарына буйсынучы оешмаларга юлланган мөрәҗәгатьләр.

3.4.3. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат бирүчеләрнең белгечләре сорала торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамәләр җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән срокта үтәлә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып торалар: ведомствоара мөрәҗәгатьләр юллау өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.4. Оешманың ведомствоара мөрәҗәгатьләр юллау өчен җаваплы вазыйфаи заты:

ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле сорала торган документларны (белешмәләрне) яки документ һәм (яисә) мәгълүмат булмаганда, баш тарту турында хәбәрнамә ала;

Гариза бирүче тапшырган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган документларны (белешмәләрне) анализлый;

Регламентның 2.8.2 пункты күздә тоткан нигезләр булганда, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

Регламентның 2.8.2 пункты күздә тоткан нигезләр булмаганда, гаризаны терки.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын килештерү Регламентның 3.3.3 пункты күздә тоткан тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып торалар: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.5 Регламентның 3.4.2, 3.4.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән.

3.4.6. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәү законнар белән билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

3.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны үтәү башлануга нигез булып дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар комплекты (мәгълүматлар) керү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) (алга таба – документларны эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат) Оешманың боерыгы белән билгеләнә.

3.5.2. Гаризаны һәм тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча, башкаручы Гариза бирүчегә тапшырылган барлык документлар (документларның күчермәләре) саклана торган шәхси эш ача.

3.5.3. Административ процедураны үтәүнең максималь срогын икедән атмаган эш көне тәшкил итә.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.6.1. Административ процедураны үтәү башлануга нигез булып, административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затның дәүләт хезмәте күрсәтүне раслый торган документны алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) (алга таба – документларны кабул итүгә җаваплы вазыйфаи зат) Оешманың боерыгы белән билгеләнә.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинет аша яисә гаризада күрсәтелгән башка ысул белән дәүләт хезмәтен электрон

хезмәттәшлек юлы белән күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураны үтәү, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имза салынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.6.2. Оешмада кабул итү (керү) сынаулары уздыру зарур булган очракта Гариза бирүчегә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинет аша, индивидуаль сайлап алу уздыруның Оешманың рәсми сайтына урнаштырыла торган графигына туры китереп, индивидуаль сайлап алу уздыру зарурлыгы турында 10 эш көне эчендә хәбәр ителә.

3.6.2.1. Индивидуаль сайлап алу уздыру көне, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат, индивидуаль сайлап алу уздыру көненә кадәр өч эш көненнән соңга калмыйча, мәгълүмат стендына һәм Оешманың рәсми сайтына урнаштырыла.

3.6.2.2. Индивидуаль сайлап алу узу өчен Гариза бирүче Оешмага алар турында мәгълүмат Гариза бирүче Бердәм порталы, Республика порталы аша алдан җибәргән гаризада күрсәтелгән документларның төп нөсхәләрен бирә.

3.6.2.3. Оешмада индивидуаль сайлап алу уздыру зарурлыгы булмаган очракта Гариза бирүчегә гариза Оешмада теркәлгән көннән алып дүрт эш көне эчендә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинет функционалы ярдәмендә дүрт эш көне эчендә килешүне имзалау зарурлыгы турында хәбәрнамә җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинет функционалы ярдәмендә дүрт эш көне эчендә килешүне имзалау зарурлыгы турында хәбәрнамә җибәрү.

3.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.7.1. Гариза бирүче Оешмага дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, Оешма хезмәткәре Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен кәгазь битендә бирә. Гариза бирүче таләбе буенча электрон документның кәгазь битендәге нөсхәсе белән бергә аңа электрон документның алынмалы-куелмалы йөрткечкә яздырып алу юлы белән ясалган нөсхәсе бирелергә яисә электрон документның нөсхәсе гариза бирүче адресына электрон почта аша җибәрелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүче килгән көнне Оешманың эш регламенты билгеләгән срокларда чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

3.7.2. Гариза бирүче Бердәм портал, Республика порталы аша дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, Гариза бирүченең шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон сурәте автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документка Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты имза куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бердәм портал, Республика порталыннан файдаланып, Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны җибәрү (тапшыру).

3.8. Техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, Гариза бирүче Оешмага җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча);

дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак, Гаризага бирүчегә бирелгән техник хатасы булган документ;

юридик көчкә ия булган, техник хата булуын дәлилләүче документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза Гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан почта юлламасы итеп (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), Бердәм портал яки Республика порталы аша җибәрелә.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи затка карауга юлланган кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртүгә җаваплы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында документларны карый һәм, Гариза бирүчедән техник хаталы документның төп нөсхәсен алып, Гариза бирүчегә шәхсән имза куйдырып тапшыра, яисә техник хата булган документның төп нөсхәсен Оешмага биргәч, документны алу мөмкинлеге турында Гариза бирүче адресына почта юлламасы белән (электрон почта аша) хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яисә хата турында теләсә кайсы мәнфәгатьле заттан җибәрелгән гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны

үтәвен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту тәртибе.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору Гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала. Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) делопроизводствоны билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүмат базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка белешмәләр файдаланыла.

Административ процедураларның сроклары, эзлеклелеге һәм эчтәлеге бозылу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук бозылуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Оешманың дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыруга җаваплы хезмәткәре, делопроизводство хезмәте хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Оешма нигезләмәсе һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыруның тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тәртибе һәм формалары.

Контроль тикшерүләр планлы (Министрлык эшенең яртыеллык яисә еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр каралырга (комплекслы тикшерүләр) яисә тикшерү Гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча булырга мөмкин.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү барышында үзләре кабул итә (гамәлгә ашыра) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплылыгы.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, Гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Оешманың дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы структур бүлекчәсе җитәкчесе гаризаларны үз вактында карамаган һәм (яисә) Регламентның 3 нче бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы була.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка дәүләт хезмәткәрләре законнар билгеләгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту (шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан) тәртибенә һәм формаларына таләпләрне сыйфатлаучы нигезләмәләр. .

Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының, дәүләт гражданлык хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Министрлыкка судка кадәр тәртиптә шикаять бирү хокукына ия.

Оешманың дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Оешма җитәкчесенә бирелә, Оешма җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр – Министрлыкка.

КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә бирелә, КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр – КФҮне гамәлгә куючыга.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, аларны бирү яисә кылу Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында күздә тотылмаган документларны яисә мәгълүматны бирүне, яки гамәлләр кылуны Гариза бирүчедән таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Гариза бирүчедән аларны тапшыру Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре күздә тотылмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә Гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында күздә тотылмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Гариза бирүчедән аларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда яки дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә әйтелмәгән документларны яисә мәгълүматны таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күздә тотылган очраклардан тыш.

5.3. Шикаять кәгазьдә яисә электрон формада язма рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (https://mincult.tatarstan.ru/), Республика порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук Гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, “Интернет” челтәреннән, КФҮнең рәсми сайтыннан, Республика порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук Гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесе һәм (яисә) хезмәткәренең исеме;

2) Гариза бирүченең – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр яки Гариза бирүченең – юридик затның – атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр,

шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), Гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр.

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән Гариза бирүченең нинди дәлилләр нигезендә килешмәве.

5.5. Кергән шикаять кергән көне артыннан килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.6. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, КФҮнең Гариза бирүчедән документларны кабул итеп алудан яки җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять бирелгән очракта, яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга карата шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Гариза бирүче Гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтү, түләтү Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында күздә тотылмаган акчаны Гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көн артыннан килүче көннән соңга калмыйча, Гариза бирүчегә язма рәвештә һәм Гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип таныган очракта, Гариза бирүчегә бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, КФҮ тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип таныган очракта, Гариза бирүчегә бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүгә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Өстәмә гомуми белем бирү программасы
буенча укуга кабул итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формасы

Теркәү номеры______

Гомуми белем бирү оешмасы
директорына

| | |
|---|---|
| Фамилия ________________________________<br>Исем____________________________________<br>Атасының исеме (соңгысы – булган очракта)_________________________________<br>______________________________________<br>Туган көне_______________________________<br>Туган урыны_____________________________<br>______________________________________ | Гражданлык _____________________________<br>Шәхесне таныклаучы документ,<br>_______________________________________<br>сериясе____________ №___________________<br>Кайчан һәм кем тарафыннан<br>бирелгән:_________________________________<br>_______________________________________<br>_______________________________________ |
| Теркәлү адресы:___________________________<br>_______________________________________<br>_______________________________________<br><br>Чынлыкта яшәү адресы:____________________<br>_______________________________________<br>_______________________________________ | Телефон (өйнеке):________________________<br><br>Телефон (кәрәзле):________________________ |

* Аерым категория затлары өчен тамгалар:
1) ятим балалар 2) ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар 3) ятим балалар исәбендәге затлар 4) ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар 5) сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар 6) инвалидлар
(кирәклесенең астына сызарга)

ГАРИЗА

_______________________________________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
Өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга
_________________________________________________________ кабул итүне үтенәм
Программаның атамасы
Баланы җайлаштырылган белем бирү программасы буенча укытуга ихтыяҗ,

инвалид балаларны Инвалидны тернәкләндерү индивидуаль программасы (булган очракта) нигезендә укытуны оештыру өчен махсус шартлар тудыру

_______________________________________________________________________________

Нигез

Дәүләт хезмәте нәтиҗәләре турында миңа болай хәбәр итүне үтенәм:

_____________________________________________________________________________

(хәбәр итү ысулын күрсәтергә)

Документларны тапшырганда таныштым:

- мәгариф эшчәнлеге алып баруга лицензия белән ___________________________

(Гариза бирүче имзасы)

- дәүләт аккредитациясе турында таныклык белән _________________________

(Гариза бирүче имзасы)

- Оешманың Уставы белән _________________________

(Гариза бирүче имзасы)

- эчке тәртип кагыйдәләре белән _________________________

(Гариза бирүче имзасы)

Үземнең шәхси мәгълүматны, балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматын эшкәртүгә ризалык бирәм. _________________________

(Гариза бирүче имзасы)

Дата “__” ___________ 20__ ел _________________________

(Гариза бирүче имзасы)

Оешманың җаваплы заты имзасы _________________________

Өстәмә гомуми белем бирү программасы
буенча укуга кабул итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Форма

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны
кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә

Кемгә: ____________________
___________________________

____________________ ____________ номерга

Сездән өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча укуга кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән түбәндәге нигезләр буенча баш тартылды:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат бирәбез:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка төрле өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Оешманың вәкаләтле хезмәткәре
_____________________________________
(имза, фамилия, инициаллар)

Өстәмә гомуми белем бирү программасы
буенча укуга кабул итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Мәгариф оешмасы
җитәкчесенә

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм:
______________________________________________________________________
(хезмәт атамасы)

Язылган:____________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат: ______________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны кушып бирәм:

1.
2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны болай җибәрүегезне үтенәм:
электрон документны E-mail адресына: _____________ җибәрү юлы белән;
кәгазь чыганактагы расланган күчермә рәвешендә почта юлламасы итеп, түбәндәге адреска:
______________________________________________________________________.

Шушының белән раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхескә һәм мин аның мәнфәгатьләрендә эш итә торган затка караган, шулай ук түбәндәрәк минем тарафтан кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага кушымта итеп бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары билгеләгән таләпләргә туры килә, гариза бирелгән вакытка бу документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләрне үз эченә ала.
Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм, телефоным: ________________.

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | ________________ | (___________________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта)) |

Өстәмә гомуми белем бирү программасы
буенча укуга кабул итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Форма

Кемгә:___________________

________________ ___________ номерга

Кабул итү турында боерыктан өземтә

Шушының белән хәбәр итәбез: “__” ____________ 20__ ел, № ________ боерык белән,
“__” ____________ 20__ ел, № ________ гариза буенча
гр. ___________________________________________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булган очракта));
өстәмә (гомуми белем бирү/һөнәр алдыннан) программасы буенча укуга кабул ителде
________________________________________________________________________________
(программа атамасы)
________________________________________________________________________________.
(Оешма атамасы)

Искәрмә:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Оешманың вәкаләтле хезмәткәре
_____________________________________
(имза, фамилия, инициаллар)

Өстәмә гомуми белем бирү программасы
нигезендә укуга кабул итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмә)

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы мәдәният министры | 8(843) 264-74-01 | mkrt@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары | 8(843) 264-74-09 | Yuliya.Adgamova@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының фәнни тикшеренүләр, инновацияләр һәм һөнәри компетенцияләрне үстерү бүлеге начальнигы | 8(843) 264-74-30 | Faniya.Kozyreva@tatar.ru |

### “Бәхетле балачак” Балалар үзәге” балаларга өстәмә белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| “Бәхетле балачак” Балалар үзәге” балаларга өстәмә белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе директоры | 8(843) 554-49-38, 8(843) 554-04-97 | kristall-kaz@mail.ru |

### «Казан хореография училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| «Казан хореография училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры | 8(843)-236-65-81; 8(843)-236-65-51 | ballet-kazan@mail.ru |

## “Николай Иванович Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы” (техникумы) урта һөнәри белем бирүче дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| “Николай Иванович Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы” (техникумы) урта һөнәри белем бирүче дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры | (843) 236-61-01 | khu@mail.ru |

## “Чаллы сәнгать колледжы” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| “Чаллы сәнгать колледжы” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры | 8(855)-271-51-91 | college_art@mail.ru |